ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23 06 2021 г. № 197

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында» 2013 елның 18 мартындагы 36 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына, аларны эшләү һәм раслау тәртибенә карата таләпләр турында» 2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы карары нигезендә, 2020 елның 29 маендагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне исәпкә алып, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты, карар бирә:

1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында» 2013 ел ның 18 мартындагы 36 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең җылылык белән тәэмин итүнең кушымта итеп бирелгән актуальләштерелгән схемасын расларга.

2. «Татэнерго» АҖгә, «Түбән Кама нефтехим» ГАҖгә, «Энергошинсервис» ҖЧҖгә, «ТАНЕКО» АҖгә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең актуальләштерелгән җылылык белән тәэмин итү схемасының раслана торган өлешенең 10 бүлегендә күрсәтелгән чиктәрләрнең гамәлдә булу зонасында бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы статусын бирергә.

3. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2019 елның 15 апрелендәге 80 номерлы «Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында» 2013 елның 18 мартындагы 36 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Нижнекамсая Правда» газетасында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
торак сәясәте бүлеге җитәкчесе

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881

Е.С. Митрошенкова